ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2021 ел № 3

2022 елда Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегендәге Кәрәкәшле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карары, Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 14 декабренә 14.00 сәгатьтә Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле торак пунктында Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев ур., 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Кәрәкәшле торак пунктында зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында су юлын ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алмаштыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

Кәрәкәшле торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү (килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктындагы Комсомол урамында җәяүлеләр басмасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга:

http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев